**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» июль, 2024 г. № 505

Ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны социальләштерүне оештыру мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия төзү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 04 мартындагы 118 номерлы карары нигезендә һәм ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны тәрбияләү һәм социальләштерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны социальләштерүне оештыру мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия төзергә.

2. Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

2.1. Ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны социальләштерүне оештыру мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия турында нигезләмә (1 нче кушымта);

2.2. Ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны социальләштерү мониторингын оештыру мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия составы (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Питрәч муниципаль районы сайтында (http://pestreci.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.С. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе Р. Ә. Сөләйманов

Карар белән расланган
________ 2024 № ________

Ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны социальләштерүне мониторинглау мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия составы

| | |
|---|---|
| Шәйхисламов Азат Сөләйманович | Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, ведомствоара комиссия рәисе |
| Харитонова Марина Алексеевна | Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге начальнигы, ведомствоара комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Гайнуллова Наталья Александровна | Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек башлыгы, ведомствоара комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Груздева Анна Алексеевна | Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге баш белгече, ведомствоара комиссия секретаре: (килешү буенча) |
| Ведомствоара комиссия әгъзалары: | |
| Бикинина Ольга Владимировна | Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең җаваплы секретаре (килешү буенча) |
| Юматова Дарья Павловна | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зеленодольск муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Бикчәнтаев Нияз Илнурович | «Питрәч районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДАУ директоры (килешү буенча) |
| Иванюженкова Анастасия Алексеевна | Россия ЭЭМ Питрәч районы буенча УУП һәм юл хәрәкәте кагыйдәләре бүлеге инспекторы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Кузнецова Марина Юрьевна | Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре бүлеге җитәкчесе<br>(килешү буенча) |
| Корбанова Ләйсән Салаватовна | Питрәч үзәк район хастаханәсе баш табибы урынбасары |